*Хисматова А.Х.,*
*Кукмара районы Янил урта гомуми белем бирү*
*мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

# *Г. Ибраһимовның халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнүе һәм татар фольклорын фәнни дәрәҗәгә күтәрү өлкәсендәге эшчәнлеге*

Татарның XX гасыр тарихы мәшһүр исемнәргә, гаҗәеп көчле талантларга бай. Ул шәхесләрнең барысын да диярлек уртак максат - туган халыкның азатлыгын, рухи яңарышын, матур киләчәген тәэмин итү берләштергән хәлдә, конкрет эшчәнлек өлкәләре төрле-төрле. Аларның бер ишләре милли азатлык хәрәкәтен оештыручылар, аның лидерлары һәм идеологлары булдылар, сәясәт дөньясында, татарның дәүләтчелеген торгызу өлкәсендә тирән эз калдырдылар. Икенчеләре милли матбугатны, драматургияне һәм театрны нигезләүчеләр, яңа әдәбиятны үстеруче иделәр, аның классиклары булып танылдылар. Өченчеләре мәгариф, фән һәм мәдәният өлкәсендә интенсив эшләделәр, татар телен, милли тарихны өйрәнүне фәнни нигезгә куйдылар. Халыкның тарихи хәтерен яңадан торгызуга хезмәт иттеләр. Галимҗан Ибраһимов исә үзенең олы таланты һәм купкырлы әдәби-фәнни иҗаты, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге белән әнә шул өлкәләрнең бөтенесен диярлек колачлап ала алды, аларның һәркайсында үз сүзен әйтеп, җуелмас эз, бай әдәби мирас калдырды.

Ул - туган халкының Россия куләмендә җәелгән инкыйлабый-азатлык хәрәкәте аша яңа тормышка барышын, шуның өчен көрәшен, шул максатка ирешү юлындагы өмет-ышанычларын, аларның югалуларын, алдану-фаҗигаләрен үзенең җәмәгать эшчәнлегендә гаять калку һәм тирән, бөтен катлаулылыгы һәм каршылыклары белән чагылдырган тарихи шәхес. Безгә Галимҗан Ибраһимов олуг язучы, тәнкыйтьче, публицист, тел - әдәбият галиме, көрәшче, оештыручы буларак яхшы таныш. Болардан тыш, ул - халык авыз иҗатын өйрәнүне, татар фольклорын фәнни нигезгә күтәрүчеләрнең берсе дә.

Үземнең хезмәтемдә Г.Ибраһимовның татар фольклористика фәнен үстерү өлкәсендәге эшчәнлеген ачыклауны төп максат итеп куйдым. Язучының халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү, татар фольклорын фән дәрәҗәсенә күтәрү өлкәсенә караган хезмәтләрен барлау, үз әсәрләрендә халык авыз иҗаты әсәрләрен куллануын ачыклау аркылы үз максатыма ирештем дип уйлыйм.

Әдәбиятыбыз үзенең барлыкка килүендә, үсешендә, яшәешендә халык авыз иҗаты, ягъни фольклорга бурычлы. Әгәр дә без үз фольклорыбызны өйрәнмәсәк, аны фәнни югарылыкка күтәрмәсәк, ул югалыр, аның белән бергә әдәбиятыбыз, мәдәниятыбыз да юкка чыгар иде. Моның мөһимлеген аңлап язучы-галимнәребез татар фольклористика фәнен үстергәннәр. Бүгенге көндә иң борынгы халык авыз иҗаты әсәрләре өйрәнелгән, китап булып

басылып чыккан һәм безнең буын да алар белән таныша ала икән – без фольклорчы, фольклористика фәненең үсешенә ярдәм иткән галимнәребезгә рәхмәтле. Алар эшчәнлеген без өйрәнергә тиеш. Минем хезмәтемнең актуальлеге дә шунда.

Революциядән соң барлык милли республикаларда һәм өлкәләрдә, аерым алганда Татарстанда да, халык авыз иҗаты әсәрләрен бастырып чыгару буенча күп кенә чаралар күрелә башлый. Бу елларда басылып чыккан әсәрләрдән иң мөһиме итеп Г.Ибраһимовның "Әдәбият кануннары" исемле хезмәтен күрсәтергә мөмкин. Бу хезмәтнең беренче басмасы 1916 елда, ә үзгәртелгән, тулылындырылган икенче басмасы 1918 елны "Сабах" ширкәтендә басылып чыга.

Г.Ибраһимов үзенең халык авыз иҗатына булган карашын әле 1910 елларда ук бик ачык итеп әйтеп биргән иде. Ул елларда әдәбият мәсьәләләренә карата язылган "Халык мосаннәфаты" исемле мәкаләсендә язучы халык авыз иҗатын белүнең әһәмиятен әйтеп, аны өйрәнүдә рус халкыннан үрнәк алырга кирәклекне алга сөрә. "Рус дөньясы, - ди ул ,моңа гомумән якын вә әһәмият күзе саладыр. Рус әдәбиятына гаид нинди бер тарихны кулга алмагыз, һәммәсендә диярлек иң башлап шул әкият вә җырлар хакында бәхәс вә шулардан нәмунәләргә очрала; бөтен кыйраәт китапларында иң башта шулар куелып, шәкертләргә гомумән тәгълим кыйлынадыр. ...Хасыйл, мәдәни рус дөньясының һәртөрле ягында моңа әһәмият биреләдер... " Аннары ул татар халык авыз иҗаты әсәрләрен дә "бер дә үзгәртмичә, халык телендә ничек сөйләнсә, шул көйгә" язып алырга чакыра. "Болар, - дип дәвам итә Г.Ибраһимов, - милли тел вә милли лөгатьнең бердәнбер хәзинәләредер. Болар эченнән татарча бик тугры тасвирлар вә җөмләләр табарбыз... Шуларны моләхаза итеп без, бер яктан, халык мосаннәфатын бер дә үзгәртми җыя барырга, вә, икенче яктан, әдип вә шагыйрьләребездән Тукаевның "Су анасы" вә "Шүрәле"се кебек шигырь вә хикәячекләрнең чыгуын теләргә тиешбез".

Г.Ибраһимовның халык иҗаты әсәрләренә карата булган менә бу мәхәббәте һәм югары бәясе аның 1916-18 елларда басылып чыккан "Әдәбият кануннары" исемле дәреслегендә тагын да ачыграк күренә. Ул анда халык әдәбияты белән язма әдәбият арасындагы якынлык һәм төп аермалар, халык әдәбиятының кыйммәте һәм аның төрләре турында шактый тулы мәгълүмат бирә. "Әдәбият кануннары" Октябрь революциясенең беренче еллары мәтбугатында татар фольклорын язма әдәбият белән бер сафка куеп тикшерү һәм аны мөһим бер фәнни өлкә итеп карау юлында ясалган зур һәм беренче адым булды.

1925-1928 елларда халык авыз иҗатын өйрәнү эшендә беркадәр җанлылык башлана. Татар фольклористикасында төп юнәлешне күрсәтүчеләрнең берсе ул вакытта Татарстан республикасында фән һәм культура эшләренең башында торучы Г.Ибраһимов була. 1926 елда "Безнең юл" журналында аның "Тел, әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы. Татар халык әдәбияты турында" исемле зур гына мәкаләсе басылып чыга.

"Бездә халык әдәбиятын җыю, тикшерү, тәртипләү эше тел-әдәбият мәсьәләләренең бик кирәкле бер тармагы буларак хәзерге көндәге гыйльми-әдәби эшләребезнең алдынгыларыннан итеп мәйданга куелырга тиешледер дип беләм", - ди ул мәкаләсенең башында ук. Аннары, халык авыз иҗаты белән кызыксыну эшенең соңгы вакытларда киңәйгәннән-киңәя баруына туктала: "Тел,әдәбият белән шөгыльләнүчеләребезнең башкалары да бу хакта азмы-күпме хезмәт бирә килделәр. Соңгы елларда моңа әһәмият бирү аеруча төс алды. Ләкин бастырып чыгара алмау мәсьәләсе бәйләп торадыр.

Татар халык авыз иҗатын өйрәнү эшенә Г.Ибраһимов "тик бер гыйльми назарый мәсьәлә дип кенә" карамавын аеруча басым ясап әйтә. "Халык тормышын, халыкның фикерен, икътисадын өйрәнүгә, хәзерге аталма, әдәби телнең эшләнүендә бу хезмәтнең бик зур гамәли ягы да бар дип беләм. *Телгә җиңеллек, телгә байлык, телгә сафлык, телгә төзеклек, телгә дөреслек* кебек төп максудларда бу хезмәт безгә бик зур ярдәмче булыр дип ышанам", - ди ул. Шуның белән бергә, ул татар фольклорының казан татарлары фольклоры белән генә чикләнмәвен, бәлки аның башка өлкә һәм республикаларда яшәүче татарлар арасында булган фольклор белән баетылырга,тутырылырга тиешлеген дә әйтә. "Әле бездә моңарчы җыелганы, - ди ул, - башлыча Казан татарлары эчендә җыелганнар. Хәзер башка кабиләләргә дә кул салырга кирәк. Җыйганда имлане матбугатча түгел, бөтенләй тик ишетелгәнчә язмау аркасында, кабиләләрнең сөйләшүләре аерылмый кала. Кулдагы материалларның һәммәсе бу яктан гөнаһлылар". Мәкаләдә халык авыз иҗатының коры җыйналу гына түгел, бәлки фәнни нигездә өйрәнелергә тиешлеге кат-кат әйтелә һәм төп бурычларның берсе итеп куела. Халык авыз иҗатының аерым төрләре, мәсәлән, әкиятләр, төрки халыклары һәм рус әкиятләре белән чагыштырмача өйрәнелергә кирәклеге дә читтә калмый.

Г.Ибраһимов мәкаләсе мәтбугатка чыкканнан соң, татар халык авыз иҗатын туплау һәм өйрәнү эше шактый җанланып китә. Шул ук 1926 елда М.А.Васильев һәм Г.Рәхим тарафыннан эшләнгән "Фольклор һәм халык әдәбияты җыю өчен кулланма" басылып чыга. Әлеге хезмәтемне башкарганда мин Г.Ибраһимовның әдәби әсәрләрендә халык авыз иҗаты әсәрләрен куллануын ачыкларга теләдем. Язучы “Алмачуар”, “Табигать балалары”, “Кызыл чәчәкләр” әсәрләрендә халкыбызның гореф-гадәтләрен, уеннарын чагылдыра, халык әйтемнәрен куллана. Мәсәлән, “күңел - әүлия”, “ашаганым – аш, эчкәнем – су булмый”, “гөнаһ шомлыкка каршы”, “күз-колак булып торырга кирәк” “ат җене кагылган”( “Алмачуар”дан). “Ятим бозау асрасаң, авызың-борының май итәр, ятим бала асрасаң, авызың-борының кан итәр...” ( “Кызыл чәчәкләр” дән.) Башка әсәрләрендә исә халык иҗаты әсәрләреннән бары тик халык җырларын, такмакларны гына куллана.

Башкорт, башкорт барага,
Кермә безнең арага,
Утыртырбыз бүкәнгә,
Типкәләрбез җилкәңә.

Сандугачлар килгән безгә,
Китмәсләр микән көзгә.
Язга сабан туйларына
Кайтырбыз микән без дә ( “Кызыл чәчәкләр” дән).

Урамнан узып бара,
Кашыннан күзе кара.
Керфегеннән гөлләр тама,
Күрсәм йөрәгем яна...

“Әйттер, җаный, әйттер, җаный,
Әйттерүләрең калыр.
Мин алмасам, башка алыр,
Безнең йөрүләр калыр.” (“Яшь йөрәкләр”дән).

Эзләнүләремнән чыгып, шуны әйтәсем килә: Г.Ибраһимовның халык иҗаты әсәрләрен халыкның рухи байлыгы итеп каравы, аның идея-художество үзәнчелеген дөрес билгеләү турындагы чыгышлары, хезмәтләре татар фольклористика фәненең дөрес юл белән үсеп китүенә ярдәм иткән.

Г. Ибраһимов хезмәтләрендә халык иҗаты әсәрләрен өйрәнергә, тупларга чакыра. Ләкин үз әсәрләрендә халкыбызның гореф-гадәтләрен, уеннарын чагылдырса да ( “Алмачуар”, “Табигать балалары”), халык иҗаты әсәрләреннән бары тик халык әйтемнәрен һәм җырларын гына куллана. Язучы әсәрләрен өйрәнеп, мин түбәндәге нәтиҗәгә килдем. Ул чорда революционер язучы әсәрләренә дәүләт тарафыннан цензура көчле булган, шуның нәтиҗәсендә Г.Ибраһимовның күңел түрендә халык авыз иҗаты әсәрләренә карата мәхәббәте көчле булса да, ул әсәрләренең артык халыкчан булуын теләмәгәндер.

**Әдәбият**

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда / Г. Ибраһимов. - Казан. -1975.
2. Татар халкының поэтик иҗаты. - Казан. - 1971.
3. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов / М. Хәсәнов // Татарстан. - № 8. - 2000.